| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» | | «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.04.2020 г.Лениногорск № 525

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 17 сентябрендәге 357 номерлы карары белән расланган «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә үзгәреш кертү турында

2020 елның 1 мартында кабул ителгән 35-ФЗ номерлы «Ана (гаилә) капиталы средстволарын куллануга бәйле мәсьәләләр буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» гы Федераль законга таянып, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 17 сентябрендәге 357 номерлы карары белән расланган «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1нче пунктның d пунктчасында «Опекада торучы балага компенсация билгеләү өчен, өстәмә рәвештә, бала өстеннән опека билгеләү турында җирле үзидарә органнары карарыннан өземтә тапшырыла;» сүзләрен төшереп калдырырга.

3.Әлеге карарны рәсми публикаторда - «Лениногорские вести» газетасында бастырып чыгарырга һәм «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге сайтында рәсми интернетка урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары В.В. Друкка йөкләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

И.Р. Хәйбрахманов
5-44-72